Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Иске Шөгер авыл җирлеге
Иске Шөгер авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2020 елның 20 ноябре № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлеге Иске Шөгер авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, алар саны 18 яшькә җиткән җирлек халкының гомуми санынннан 30% тан артмаска тиеш, 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- М. Җәлил, Мурзин, Калинин урамнарындагы юлларга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- территорияне механикалаштырылган һәм кулдан чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (килешү буенча эшләр, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);

3) җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка чаралар:

- тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү (территорияне коры-сарыдан һәм чүп үләненнән чабу, кардан чистарту, полосаларны минеральләштерү, сөрүлекләр һәм башка төр эшләр).;

- МТЗ-82.1 тракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, отвал алу);

- Иске Шөгер авыл мәдәният йортының терәк стенасын ремонтлау һәм территорияне тотып алу (чыгым материаллары сатып алу һәм килешү буенча түләү);

- чәчәк үсентеләре сатып алу;

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- коры-сары һәм чүп үләннәрен чабу, килешү буенча түләү;

5) җирлек халкының ялын оештыру өчен шартлар тудыру һәм авыл халкын мәдәният хезмәтләре белән тәэмин итү;

- сәхнә костюмнары сатып алу (чыгым материаллары алу, килешү буенча түләү);

- «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Иске Шөгер - җирле үзидарә бинасы, Совет урамы, 1 нче йорт, Совет урамы, 3 нче йорт буенча урнашкан балалар бакчасы бинасында, М. Җәлил урамы, 33 нче йорт, буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова